ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 г. № 368

Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының
2017 елның 10 мартындагы 92 номерлы Карары белән раслаган
«мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә
ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга
компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга өстәмә компенсация бирү тәртибен унификацияләү максатыннан, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенең яңа редакциясен раслау турында» 2017 елның 10 мартындагы 92 номерлы карары белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибендә 3 бүлектәге 3.4. пунктына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертеп тулыландырырга:

"Килешү (контракт) булмаган очракта, компенсация түләүләрен күчерү гариза бирүче күрсәткән теләсә кайсы исәп-хисап счетына башкарыла".

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе башлыгына (В.Г. Сафиуллина) әлеге карарны мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары җитәкчеләренә җиткерергә һәм аны гамәлгә ашыруга чаралар күрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р. Р. Гильмутдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**